ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.12.2022 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3627**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 декабрендәге «2022 елга Зеленодольск шәһәре предприятиеләреннән үзәклә штерелгән су бүлеп бирү системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агып төшүче сулар составының нормативларын раслау турында» 3303 номерлы карары гамәли көчендә булуы турында

2011 елның 07 декабрендәге «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 416-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең 2018 елның 05 октябрендәге СВ 32.12.18.59 номерлы әйләнә-тирә мохиткә (су объектларына) зарарлы(пычраткыч) матдәләр агызуга рөхсәт язуы (лицензиясе) нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 декабрендәге «2022 елга Зеленодольск шәһәре предприятиеләреннән үзәкләштерелгән су бүлеп бирү системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агып төшүче сулар составының нормативларын раслау турында» 3303 номерлы карарының гамәли көчен 2023 елның 10 сентябренә кадәр озайтырга.
2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга, «Зеленый Дол» һәм «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В. Старостин